Мордовия Республикасы Хокvмәте Рәисе урынбасары (Заместитель Председателя Правительства РМ) Батыр Эмеевич Эмеев эшкуар Айдар Фаиль улы Шафеевны шәхси кабул итте. Очрашуда ул бер ел элек, дусты белән бергә, гаилә сабын житештерv производствосын ачканын сойләде.   Айдарны сату базарларын кинәйтv, шулай ук торле кvргәзмәләрдә, форумнарда һәм чараларда катнашу кызыксындыра. Очрашу барышында анын белән маркетплейска чыгу момкинлеге һәм «Магнит» челтәренә житештерvне оештыру турында фикер алыштылар. Батыр Эмеев vз ягыннан барлык кирәкле ярдәмне кvрсәтергә вәгъдә бирде.
Шулай ук «Шафеев» ИП продукциясе барлык экологик таләпләргә жавап бирә һәм «Халәл» сертификаты алган, әмма шуннан сон да житештерvче яна технологияләрне сынап карауны һәм кертvне дәвам итә; продуктнын сыйфатын даими кvтәрә.
Үз эшенә карата мондый монәсәбәт тирән хормәт уята, шулай ук сәламәтлек момкинлекләре чикләнгән булуга карамастан, ул авырлыклар алдында туктамый һәм vсеш очен барлык юлларны куллана. Анын тарихы кvпләр очен vрнәк һәм мотивация булып хезмәт итәр дип ышана Б.Э.Эмеев.